ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 1.1[1] һәм 8.2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 мартында
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7, № 12 (III өлеш); Ватаным Татарстан, 2015, 7 март) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.1[1] статьяның 4 пунктында “җирле үзидарә органнарының” сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 8.2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“8.2 статья. **Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар**

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.4 статьясындагы 1 өлешендә, 19.4[1] статьясындагы 1 өлешендә, 19.5 статьясындагы 1 өлешендә, 19.7 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне түбәндәгеләр төзи:

1) региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген), шулай ук федераль дәүләт күзәтчелеге өлкәсендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма

органнарының структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм белгечләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының территориаль органнары җитәкчеләре һәм белгечләре, шулай ук вазыйфаи бурычларына эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) башкару керә торган башка вазыйфаи затлар;

2) муниципаль районнарда, шәһәр округларында муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда – муниципаль районнар, шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре, аларның беренче урынбасарлары, урынбасарлары, муниципаль районнар, шәһәр округлары башкарма комитетларының структур бүлекчәләре җитәкчеләре, аларның урынбасарлары, шулай ук вазыйфаи бурычларына муниципаль контрольне башкару керә торган муниципаль районнар, шәһәр округлары башкарма комитетларының башка вазыйфаи затлары;

3) җирлекләрдә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда – җирлекләр башлыклары, җирлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләре, җирлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләре урынбасарлары (секретарьлары), шулай ук вазыйфаи бурычларына муниципаль контрольне башкару керә торган җирлекләрнең башкарма комитетларының башка вазыйфаи затлары.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 елның 11 апреле
№ 25-ТРЗ